РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ КАРАР

25 ноябрь , 2024 ел № 32

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советының 2018 елның 17 декабрендәге 27 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясына һәм «Ришвәтчелеккә каршы көрәш турында» Федераль законның 13.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 228-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль шәһәре Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советының 2018 елның 17 декабрендәге 27 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 12 статьясындагы 1 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) «Ришвәтчелеккә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны үтәргә;»;

1.2. Нигезләмәнең 12 статьясындагы 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Әлеге статьяның 6 пункты нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә «Ришвәтчелеккә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе

территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларның счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 мендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон беләнн билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә аңа карата җаваплылык чарасы куллану турындагы гариза белән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Советына яисә судка мөрәҗәгать итә.»;

1.3. Нигезләмәнең 12 статьясына түбәндәге эчтәлекле 7.1 һәм 7.2 пунктларын өстәргә:

«7.1. Үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган депутатка карата, әгәр бу белешмәләрне бозу җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итеп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфасыннан азат итү;

3) аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләре вакыты тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.

7.2. Депутатка карата әлеге статьяның 7.1 пунктчасында күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев